**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай район Советы КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 141-16 «14» апрель 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2013 елның 22 октябрендәге 268-37 номерлы «Азнакай муниципаль районы хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү системасын камилләштерү турында» карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Президентының 2013елның 26 сентябрендәге ПУ-943 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган, Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү турында» Указының үз көчен югалтуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 22 мартындагы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә акчалата хезмәт хакы түләү турында » ПУ-239 номерлы Указы басылып чыгуга бәйле рәвештә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының түбәндәге крарары үз көчен югалткан дип танырга:

- 2013 елның 22 октябрендәге 268-37 номерлы «Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган, җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү системасын камилләштерү турында».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru//. http://pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин